РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г. Нижнекамск, пр. Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 5 2022 елның 4 феврале

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 71 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248–ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 71 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

66 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Контроль чарасы актында бәян ителгән фактлар һәм нәтиҗәләр белән килешмәгән очракта, контрольдә тотылучы зат әлеге Нигезләмәнең V бүлегендә каралган тәртиптә актка шикаять бирергә хокуклы»;

68 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«68. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, контрольдә тотылучы затларның хокукларын бозуга китергән Контроль органының вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына), Контроль органы карарларына, Россия Федерациясе законнары нигезендә, контрольдә тотылучы зат тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин»;

69-82 пунктларны төшереп калдырырга;

Нигезләмәгә 3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта).

2. Әлеге карар, кушымта нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Нигезләмәгә 3 нче кушымта 2022 елның 1 мартыннан да соңга калмыйча үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары А.В.Умников

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2022 елның 4 февралендәге
5 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы
территориясендә муниципаль
контроль турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

Муниципаль җир контроленең
төп күрсәткечләре һәм индикатив күрсәткечләре

| Төп күрсәткечләр | Максатчан кыйммәтләр |
|---|---|
| Ачыкланган җир законнарын бозулар арасыннан бетерелгән бозулар проценты | 70% |
| Чираттагы календарь елына планлы контроль чаралар үткәрү планын үтәү проценты | 100% |
| Контроль чаралар үткәргәндә, муниципаль контроль органы һәм (яки) аның вазыйфаи заты гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезле шикаятьләр проценты | 0% |
| Гамәлдән чыгарылган контроль чаралар нәтиҗәләре проценты | 0% |
| Алар буенча тиешле административ йогынты чаралары күрелмәгән нәтиҗәле контроль чаралар проценты | 5% |
| Муниципаль контроль органы материаллары буенча административ җәза билгеләү турында кертелгән суд карарлары проценты | 95% |
| Муниципаль контроль органы тарафыннан чыгарылган карарларның гомуми саныннан административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча суд тәртибендә гамәлдән чыгарылган карарларның проценты | 0% |

Чаралар үткәрү параметрларын характерлаучы индикатив күрсәткечләр:

Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда, түбәндәге индикатив күрсәткечләр билгеләнә:

1) хисап чорында үткәрелгән планлы контроль чаралар саны;

2) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш контроль чаралар саны;

3) хисап чорында контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килү-килмәүне ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан читләшүе нигезендә үткәрелгән планнан тыш контроль чаралар саны;

4) хисап чорында үткәрелгән хезмәттәшлек белән контроль чараларның гомуми саны;

5) хисап чорында үткәрелгән ККЧның һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек итү белән контроль чаралар саны;

6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль чаралар саны;

7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

8) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;

9) хисап чорында аларның нәтиҗәсе буенча мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль чаралар саны;

10) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль чаралар саны;

11) хисап чорында контроль чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында контроль чаралар үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чорында алар буенча прокуратура органнары тарафыннан килештерүдән баш тарткан контроль чаралар үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;

15) хисап чоры ахырына һәр хәвеф-хәтәр категориясе буенча хәвеф-хәтәр категориясенә кертелгән исәпкә алынган контроль объектлары саны;

16) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затларның саны;

17) хисап чорында аларга карата контроль чаралар үткәрелгән исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

18) хисап чорында аларга карата контроль органы тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләр саны;

19) хисап чорында суд тәртибендә контрольдә тотылучы затлар тарафыннан җибәрелгән контроль органнарының вазыйфаи затларының карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмавын) дәгъвалау турында дәгъва гаризалары саны;

20) хисап чорында алар буенча игълан ителгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән, суд тәртибендә контрольдә тотылучы затлар тарафыннан җибәрелгән контроль органнарының вазыйфаи затларының карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмавын) дәгъвалау турында дәгъва гаризалары саны;

21) хисап чорында муниципаль контрольне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозу белән үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль чаралар саны.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары А.В.Умников